**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» марта 2019 с. Тюлячи № 163

Теләче муниципаль районы территориясендә «Торак – 2019» күзәтчелек-профилактика операциясе уздыру турында

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Күзәтчелек эшчәнлеге идарәсе һәм профилактика эше Дәүләт идарәсенең Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге районара бүлекчәсе (МОНД) һәм профилактика эше өлкән инспекторының 2019нчы елның 25нче гыйнварындагы 5нче санлы хатын караганнан соң, 1994нче елның 21нче декабрендәге 69нчы санлы «Янгын куркынычсызлыгы турында»гы Федераль закон, 2003нче елның 06нчы октябрендәге 131нче санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон нигезендә, торак фондында янгын чыгуларны һәм кешеләрнен үлемен кисәтү максатыннан,

КАРАР БИРӘМ:

1. Теләче муниципаль районында «Торак – 2019» күзәтчелек-профилактика операциясе уздырырга.
2. Кушымта № 1 буенча «Торак – 2019» операциясе әзерләү һәм уздыру планын расларга.
3. Теләче муниципаль районы территориясендәге торак секторны тикшерү буенча профилактика чаралары үткәрү өчен Кушымта № 2 буенча 13 профилактика төркеме составын расларга.
4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Нурмөхәмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Кушымта № 1
Теләче муниципаль
Районы Башкарма комитетының
2019 елның 21.03 163 санлы
Карары белән расланган

Теләче муниципаль районы территориясендә «Торак – 2019» күзәтчелек-профилактика операциясе әзерләү һәм уздыру
ПЛАНЫ

| № п/п | Чаралар исемлеге | Башкару вакыты | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1. | «Торак – 2019» операциясен үткәрү турында «Теләче» газетасында бастырып чыгару | 2019 елның 01.02 кадәр | Күзәтчелек эшчәнлеге районара бүлекчәсе (МОНД) (килешү буенча) |
| 2. | Җирле үзидарә органнары, эчке эшләр, социаль яклау органнары, электрчелтәре, газ хезмәте һәм башка күзәтчелек органнары белән берлектә, массакүләм мәгълүмат чараларын, халыкны һәм җәмәгатьчелекне дә җәлеп итеп, күп балалы гаиләләр һәм ялгыз өлкән яшьтәгеләр, халыкның социаль яктан имин булмаган катламы һәм спиртлы эчемлекләр, наркотиклар кулланучыларның яшәү урыннарын, яшәү урыны булмаган затларның торак урыннарын тикшерүне оештырырга, мондый затларның яшәү урыннарында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрергә. Алар белән янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү буенча профилактик әңгәмәләр үткәрергә | Ел дәвамында | МОНД, 134 ПСЧ ФГКУ «7 ОФПС по РТ», Олы Нырсы аерым янгын посты, Россия ЭЭМ Теләче районы бүлекчәсе, халыкны социаль яклау бүлеге, электр челтәре, газ хезмәте, ирекле янгын сүндерү оешмалары әгъзалары һәм авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 3. | Янгын чыгу куркынычы булган күпкатлы йортларда янгынга каршы чараларны, 2007 елның 21 июлендәге 185 санлы «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформлауга булышу фонды турында»гы Федераль законны тормышка ашыру кысаларында, торакфондына капиталь ремонт үткәрү буенча муниципаль программаларга кертү буенча эш оештырырга; аларның үтәлешенә һәм янгынга каршы башкарыла торган чараларның сыйфатына контроль урнаштырырга | Ел дәвамында | МОНД (килешү буенча) |
| 4. | Торак фондында һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | Ел дәвамында | МОНД (килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | буенча үткәрелүче чараларны һәм проблемалмары мәсьәләләрне массакүләм мәгълүматның басма чараларында, теле һәм радиоканалларда яктыртуны оештырырга. Халыкка янгыннар турында хәбәр итеп торуны, көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чараларын җиткерүне оештырырга. Җирле үзидарә органнарына янгынга каршы тематика буенча агитация һәм пропаганда материаллары (белеш мәлекләр, мәгълүмат кәгазьләре, тәкъдимнәр) эшләүдә методик ярдәм күрсәтергә, аларны почта элемтәсе, торак оешмалары, халыкны социаль яклау хезмәткәрләре, полициянең участок вәкаләтлеләре аша халыкка таратуны оештырырга | | |
| 5. | Торак фонды һәм торак пунктларның янгынга каршы халәте турындагы мәгълүматны гомумиләштерүне һәм анализлауны оештырырга. Җирле үзидарә органнары, торак оешмалары җитәкчеләре адресына торак фондында һәм торак пунктларында янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү турында тәкъдимнәр җибәрергә. Үткәрелә торган тикшерүләр турында прокуратура органнарына җиткерергә | Ел дәвамында | МОНД (килешү буенча) |
| 6. | Торак фондында һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләрен гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча муниципаль комиссияләр утырышларында карарга | Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча | Комиссия әгъзалары, янгын чыгу очраклары арткан авыл җирлекләре башлыклары |
| 7. | Торак пунктларда йорт саен йөреп, халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтергә, инструктаж үткәрү журналына кул куйдырып, белешмәлекләр өләшергә | Ел дәвамында | МОНД, «ТР буенча федераль янгын хезмәте 7 бүлеге» федераль дәүләт казна учреждениесенең 134 янгын часте һәм хезмәте, Олы Нырсы аерым посты,Россия ЭЭМ Теләче районы бүлекчәсе, халыкны социаль яклау бүлеге, электр челтәре, газ хезмәте, ирекле янгын сүндерү оешмалары әгъзалары һәм авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | Халык күп йөри торган урыннарда, мәгълүматны әледән-әле яңартып, «Торакны янгыннардан саклагыз» дигән тематик стендлар булдырырга | Ел дәвамында | МОНД, 134 ПСЧ ФГКУ «7 ОФПС по РТ», авылҗирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 9. | Торак фондының янгын куркынычсызлы гы хәле һәм кешеләрнең үлемен кисәтү турында экспресс-мәгълүмат эшләп таратырга | 2019 елның 25.01 – 2019 елның 31.12 | МОНД, 134 ПСЧ ФГКУ «7 ОФПС по РТ», Олы Нырсы аерым посты, авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 10. | Барлык торак пунктларда да янгыннарга профилактика мәсьәләләренә багышлап гражданнар җыеннары уздырырга | Расланган график буенча | МОНД, 134 ПСЧ ФГКУ «7 ОФПС по РТ», авылҗирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 11. | Мәктәп укучылары, мәктәпкәчә учреждениеләрдәге балалар белән очрашулар оештырып, балалар шаянлыгы аркасында чыгучы янгыннарга профилактикага багышланган әңгәмәләр уздырырга | Ел дәвамында | МОНД (килешү буенча), район мәгариф бүлеге |
| 12. | Районда һәм республикада чыккан янгыннар турында экспресс-мәгълүмат эшләп, дин тотучылар арасында янгынга профилактикада куллану өчен, дини конфессияләр җитәкчеләре адресына җибәрергә | 2019 елның 25.01 – 2019 елның 31.12 | МОНД (килешү буенча) |

Кушымта № 2
Теләче муниципаль
Районы Башкарма комитетының
2019 елның 21.03 163 санлы
Карары белән расланган

## Теләче муниципаль районы территориясендә торак секторны тикшерү буенча профилактика чаралары уздыру өчен профилактик төркемнәр составы

| № п/п | Оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр исемлеге | Профилактика төркеме әгъзалары саны | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы ТР буенча күзәтчелек эшчәнлеге идарәсе һәм профилактик эш Дәүләт идарәсенең Саба һәм Теләче районара күзәтчелек бүлеге | 2 | |
| 2. | «7 ОФПС по РТ» Федераль дәүләт казна учреждениесенең 134нче янгын-коткару часте | 30 | |
| 3. | «ГО ПО РТ»ның Олы Нырсы аерым посты | 7 | |
| 4. | Россия ЭЭМ Теләче районы буенча бүлекчәсе | 4 | |
| 5. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге | 8 | |
| 6. | Авыл җирлекләре башлыклары, ирекле янгын сүндерү командалары әгъзалары | 13 | |
| 7. | Профилактика төркемнәренең гомуми саны | 13 | |